**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 5 мартындагы 528 номерлы карары**

**2025 елга гражданнар кеременең һәм салым салынырга тиешле милек хакының максималь күләмен раслау турында**

Россия Федерациясе Торак кодексының 14 статьясы, Татарстан Республикасының 2015 елның 16 мартындагы 13-ТРЗ номерлы «Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем килешүләре буенча гражданнарның торак урыннары алу хокукларын гамәлгә ашыру турында»гы законы, әлеге закон кушымтасында бирелгән Гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданинга туры килә торган керемнең, гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче гражданин милкендә булган һәм салым салынырга тиешле милек хакының максималь күләмен билгеләү методикасы нигезендә, шулай ук Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының 40 статьясына таянып, **карар бирәм**:

1. 2025 елга социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем килешүләре буенча гражданнарны торак урыннары алуга мохтаҗлар дип тану турында карар кабул итү өчен гражданнар кеременең һәм салым салынырга тиешле милек хакының түбәндәге максималь күләмен билгеләргә:

1.1. гаилә әгъзалары милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының максималь күләме:

1.1.1. ялгыз яшәүче гражданин өчен – 2 550 312,0 сум;

1.1.2. ике кешелек гаилә өчен – 5 100 624,0 сум;

1.1.3. өч кешелек гаилә өчен – 7 650 936,0 сум;

1.1.4. дүрт кешедән торган гаилә өчен –10.201 248,0 сум;

1.1.5. биш кешедән торган гаилә өчен – 12 751 560,0 сум;

1.1.6. алты кешелек гаилә өчен – 15 301 872,0 сум;

1.1.7. җиде кешелек гаилә өчен – 17 852 184,0 сум;

1.1.8. сигез кешелек гаилә өчен – 20 402 496,0 сум;

1.1.9. тугыз кешелек гаилә өчен – 22 952 808,0 сум;

1.1.10. ун кешедән торган гаилә өчен – 25 503 120,0 сум;

1.1.11. унбер кешелек гаилә өчен – 28 053 432,0 сум;

1.1.12. унике кешедән торган гаилә өчен – 30 603 744,0 сум;

1.2. гаиләнең һәр әгъзасына яки ялгыз яшәүче гражданинга туры килә торган уртача айлык җыелма керемнең максималь күләме – 57 894,0 сум.

2. Казан шәһәре Башкарма комитетының район администрацияләре башлыклары Р.Х.Шәмсетдиновка, А.И.Салиховка, В.В.Жаворонковка һәм Р.Р.Фәтхетдиновка гражданнарны социаль файдаланудагы торак фондыннан торак урыннарны наем шартнамәләре буенча торак урыннары алуга мохтаҗлар буларак исәпкә куйганда, әлеге карарның 1.1 һәм 1.2 пунктчаларында күрсәтелгән гражданнар кеременең һәм милек хакының максималь күләмен кулланырга.

3. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.Ә.Гыйниятуллинга йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**